**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ШАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**НОВОШАШИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ**
**ПОСЕЛЕНИЕ**
**АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Новые Шаши. Тел. 3-23-23

КАРАР

31 октябрь 2025 ел № 6

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге **Чишмәле Сап** торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Уставы белән **карар чыгарам:**

1. 2025 елның 14 нче ноябренә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты Татарстан урамында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 елның 15 нче ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты Тукай урамында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты – 14 ноябрь 2025 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты – 15 ноябрь 2025 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Чишмәле Сап авылы, Татарстан ур.,14 нче йорт, авыл клубы;
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итергә:
- 2025 елның 05 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Яңа Шашы авылы, Яшьләр урамы, 13 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Чишмәле Сап торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Чишмәле Сап торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итергә;

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:
"Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү. (Чишмәле Сап авылында чишмә ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Коеларны төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Чишмәле Сап авылында коены ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

"РИЗА" "КАРШЫ"

Сез, 2024 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, түбәндәге җирле сорауларны чишүгә юнәлтергә ризамы:

3) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.
(Чишмәле Сап авылында һәйкәл территориясен яшелләндерү (яшел утыртмалар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); (Чишмәле Сап авылы балалар мәйданчыгын төзкләндерү (җиһазлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); Чишмәле Сап авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

"РИЗА" "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталыда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Чишмәле Сап авылы Татарстан урамы 14 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.
7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы: М.С.Сабирҗанов